СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**22.11.2018 ел** **№15**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2014 елның 05 маендагы 82.3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов